**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Верхне-Чершилинского**
**сельского поселения**
**Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районының Югары**
**Чыршылы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

26.08.2024

№ 11

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015 елның 21 декабрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гараж берләшмәләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 2 пункты, Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015 елның 21 декабрендәге 12 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 нче кушымтаның 11 пунктында “, яисә физик затларның гомерлек мирас итеп биләгән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануында, әгәр мондый җир кишәрлеге әлеге Кодексны гамәлгә кертү көненә кадәр бирелгән булса һәм шул ук вакытта мондый җир кишәрлеге хосусый милектә була алмый икән“, сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3.3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Камалетдинов